Хәерле көн, хөрмәтле Илдар Шәүкәтович!

Хөрмәтле коллегалар!

Баулы муниципаль районы Татарстан Республикасының Көньяк-көнчыгышында урнашкан һәм Оренбург өлкәсе, Башкортостан Республикасы белән чиктәш. Район аркылы "Казан-Оренбург" федераль трассасы һәм М5 "Мәскәү-Чиләбе" трассасы уза.

2014 елда районда 43800 декалитр алкогольле продукция сатылган, бу 2013 ел белән чагыштырганда 81 процент тәшкил итә. Сатылган аракы күләме 27600 декалитр, яки аннан алдагы елга карата 77 процент. Лицензияле сәүдә нокталары районда 7 берәмлеккә артты. Бу үткән ел белән чагыштырганда 106 процент тәшкил итә.

Районда җан башына 12,2 литр алкогольле продукция туры килгән. Бу 2013 ел күрсәткеченә карата 81 процент дигән сүз, ул чорда җан башына 15 литр булган.

Алкогольле продукция сату күләме кимүенең сәбәпләре берничә:

1) аракының хакы 170 сумнан 220 сумга кадәр кыйммәтләнүе;

2) Баулы муниципаль районы аша үткәрелүче Казахстан Республикасында җитештерелгән легаль булмаган алкогольле продукциянең күләме артуы. Әлеге аракы турыдан-туры Казахстаннан бик түбән бәя белән китерелә. Район территориясендә Казахстан Республикасында җитештерелгән аракының 130-150 сумга кулдан сатылуы ачыкланды. (Казахстанда ул 70-80 сум тора).

2014 елда районда легаль булмаган аракы алып килүнең 51 очрагына чик куелды, 19 951 литр алкогольле продукция алынды. Бу Баулы муниципаль районы хезмәтләренең, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Әлмәт территораль органы һәм Баулы районы эчке эшләр бүлегенең үзара килешеп эшләве нәтиҗәсендә мөмкин булды.Әлеге вакытта Баулы полиция бүлеге складында Казахстан Республикасында җитештерелгән 20872 шешә алкогольле продукция саклана, суд органнары 2014 елда 16200 литр алкогольле продукцияне конфисковать иттеләр. Административ хокук бозулар турында 42 материал суд органнарына җибәрелде.

Гражданнарга административ хокук бозу турында беркетмәләр төзелә, материаллар судка җибәрелә. Нәтиҗәдә хокук бозучылар,алкогольле продукция конфискацияләнеп, 4 мең сум штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылалар.

Аларда Баулы муниципаль районында Татарстан Республикасында җитештерелгән алкогольле продукцияне сату күләмен арттыру, Казахстан Республикасы алкогольле продукциясен, “ике төрле максаттагы” спиртлы продукцияне, шәхси хуҗалыклардан спиртлы эчемлекләр, ягъни көмешкә сатуга юл куймау сораулары каралды.

2014 елның декабрендә Республика территориясендә “Легаль булмаган алкоголь” айлыгы үткәрелде, Татарстан Республикасы алкоголь базарын тотрыклы итү буенча Дорожная карта расланды. Әлеге Юл картасына ярашлы рәвештә Баулы муниципаль районы башкарма комитеты алкогольле һәм спиртлы продукциянең легаль булмаган әйләнешенә чик кую буенча түбәндәге чараларны үткәрде.

Икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге мобиль төркемнәр составында Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе Әлмәт территориаль органы һәм Баулы районы полиция хезмәткәрләре белән берлектә рейдлар оештыруда һәм аларның эшендә катнашты.

Шулай ук “ике төрле максаттагы” спиртлы сыекчаларны ачыклау нияте белән атна саен аптекаларда тикшерүләр үткәрелә. Барлыгы 9 аптека тикшерелде. Шуның нәтиҗәсендә 100 миллилитр күләмле “ике төрле максаттагы” косметология продукциясе аптекаларда сатудан алынды.

Инфраструктура үсеше бүлеге такси коллективларында этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция сатуга юл куймау турында инструктаж үткәрде.

Алкогольле продукцияне законсыз сату ихтималы булган биналарны торак булмаган фондка күчерүгә рөхсәт кәгазьләре тикшерелде. Биналарны Торак фондтан сәүдә объектлары категориясенә күчерүгә рөхсәт алу аерым контрольдә тора, шуның белән бәйле рәвештә районда 2014 елда алкогольне лицензиясез сату очраклары теркәлмәде.

Авыл җирлекләрендә башлыклар халык арасында профилактика һәм аңлату эше үткәрделәр. 2014 елда шәхси хуҗалыкларда көмешкә сатуның 4 факты ачыкланды.

Легаль булмаган алкогольле продукция әйләнешен киметүгә юнәлдерелгән барлык чаралар турында мәгълүмат “Баулы телерадиокомпаниясе” җирле телевидениесе аша күрсәтелде, “Хезмәткә дан” (“Слава труду”) газетасында басылды һәм Баулы муниципаль районы рәсми порталында урнаштырылды.

Нәтиҗә ясап, хөрмәтле Илдар Шәүкәтович, алкоголь базарындагы хәлне тотрыклы итү эше минем шәхси контролем астында тора. Шуңа бәйле рәвештә 2015 елга түбәндәге карарлар кабул ителде:

– Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы карарын тормышка ашыру һәм алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендәге хәлне контрольдә тоту Советы кысаларында Баулы муниципаль районы башкарма комитетының күзәтчелек итү һәм хокук саклау органнары белән уртак эшенә зур игътибар бирергә;

– Баулы муниципаль районы башкарма комитетына Дәүләт алкоголь инспекциясе Әлмәт территориаль органы белән берлектә авыл җирендә сәүдә объектлары, шул исәптән алкогольле продукция сатучы кибетләр санын киметмәү эшен дәвам итәргә;

– Баулы муниципаль районында этил спиртының, алкогольле һәм спиртлы продукциянең легаль булмаган әйләнешен булдырмау ведомствоара комиссиясенең эшен активлаштырырга.

Шуңа да карамастан, республика югарылыгында хәл итүне көткән сораулар бар. Ялган һәм легаль булмаган алкоголь китереп сатуга эшләүче социаль челтәрләрне һәм сайтларны мониторинглау һәм ябу мөһим, чөнки күп очракта ялган продукция бик мобиль рәвештә, турыдан-туры автомобильләрдән сатыла.

Шуның белән минем чыгышым тәмам.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!